Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

26 октябрь, 2020 ел № 1

Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пановка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 138/92 номерлы Пановка авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Пановка авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1. Пановка авылында гражданнар җыены өч этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2020 елның 13 ноябрендә 16.00 сәгатьтә 1 Май урамы, 6 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшел, Мусин, Беренче Май урамнары, Үзәк урамының 1-14 номерлы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2020 елның 14 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 21 йорт адресы буенча урнашкан йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Үзәк урамының 16 - 31 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2020 елның 14 ноябрендә 16.00 сәгатьтә Тукай урамы, 3 нче йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Тукай, Яңа, мәктәп урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2021 елда Пановка авыл җирлеге Пановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш

хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, 2 группа эшләмәүче инвалидларны, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- Пановка торак пункты территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Пановка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев